**СОВЕТ СОКУРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422622 с.Сокуры,
ул. Школьная, д.1
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКУРЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422622 Сокуры авылы,
Школьная урамы, 1 а нчы йорт,
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**2024 елның 06 марты** **10 номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022елның 12 декабрендәге 61 номерлы Сокуры авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (22.08.2023ел 29 номер, 23.11.2023 ел 62 номер карарларындагы үзгәрешләр белән)**

«Россия Федерациясе бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 628-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлеге советы карар кабул итте**:**

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау турында»2022 елның 12 декабрендәге 61 номерлы Сокуры авыл җирлеге карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә;

1) **7 статьяның 6 өлеше** түбәндәге эчтәлектәге пунктча белән тулыландырырга:

Бюджет акчаларының баш идарәчесе:
"Электрон бюджет" иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында, капитал салуларын финанс белән тәэмин итү (финанслаштыру) чыганагы федераль бюджет акчалары булган, капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез милек объектлары турында белешмәләр формалаштыра;

2) **27 статьяның 7 өлешендәге 5 абзацтагы сүзләр**
"Федераль адреслы инвестиция программасында каралган" төшереп калдырырга, "Федераль адреслы инвестиция программасына кертелгән чараларны (зурайтылган инвестиция проектларын) детальләштерүгә бәйле рәвештә"сүзләрен " капиталь төзелеш объектлары, күчемсез мөлкәт объектлары реестрына кертелгән белешмәләрне детальләштерүгә бәйле рәвештә" сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Сокуры**
**авыл җирлеге Советы рәисе Р.Н. Газизуллин**